**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҮЗӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**
**Дүртенче чакырылышның чираттан тыш утырышы**

**Үзәк бистәсе** **№ 82** **«15» ноябрь 2021 ел**

**Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге советының 16.06.2015 ел № 235нче «Дәүләт милке чикләнмәгән Үзәк авыл җирлеге муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында.**

«Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына линияле объектларны урнаштыруны гадиләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 августындагы 341-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге советының 16.06.2015 ел № 235нче «Дәүләт милке чикләнмәгән Үзәк авыл җирлеге муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Үзәк авыл җирлегенең муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турында нигезләмәнең 12.1 пунктында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән идарә итү һәм эш итү тәртибе хакында "сервитут" сүзләреннән соң, "гавами сервитут" сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә халыкка җиткерергә.

Татарстан Республикасы Теләче
муниципаль районы Үзәк
авыл җирлеге башлыгы: В.Н.Котников